КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 сентябрь г.Казань № 860

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 ел, 30 декабрь, 1281 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 ел, 30 декабрь, 1281 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктта татар текстында «гамәлгә ашыра» сүзләре алдына «, шул исәптән рискка юнәлдерелгән алымны кулланып» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ – $5^3$ нче пунктлар өстәргә:

«$5^1$. Төбәк дәүләт нәсел күзәтчелеген гамәлгә ашырганда рискка юнәлдерелгән алымны куллану максатларында, юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда рискка юнәлдерелгән алымны куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 17 август, 806 нчы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 803 нчы карары) белән расланган Юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген

рискның билгеле бер категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре нигезендә рискның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.

$5^{2}$. Юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү, нәселле терлекчелек өлкәсендә эшчәнлек алып баручы юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең мөмкин булган үтәлмәве аркасында салынган потенциаль тискәре зыяннарның авырлыгын исәпкә алып, Министрлык боерыгы белән гамәлгә ашырыла.

Министрлыкның юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү турындагы боерыгы булмаганда, юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеге түбән рисктагы категориягә кертелгән дип санала.

$5^{3}$. Урта рисктагы категориягә юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең нәселле терлекчелек өлкәсендә: нәсел репродукторлары, нәсел заводлары, җитештерүчеләр орлыкларын саклау һәм сату буенча нәсел предприятиесе (төбәк) – гамәлгә ашырыла торган эшчәнлеге керә.

Уртача рисктагы категориягә юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең авыл хуҗалыгы хайваннарын ясалма орлыкландыру буенча, оешмаларның эмбрионнарны трансплантацияләү буенча эшчәнлеге керә.

Түбән рисктагы категориягә юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең нәсел эше буенча, оешмаларның (ипподром, сөт сыйфатын селекцион тикшерүдә тоту лабораториясе, молекуляр-генетик экспертиза лабораториясе, иммуногенетик экспертиза лабораториясе, төбәк мәгълүмати-селекция үзәкләре) продукция продуктлылыгы дәрәҗәсен һәм аның сыйфатын исәпкә алу, тикшерүдә тоту, бәяләү буенча эшчәнлеге керә.»;

6 нчы пунктның дүртенче – бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенә караган терлекчелектә күзәтчелек итү буенча секторының бер үк вакытта вазыйфасы буенча Татарстан Республикасының нәселле терлекчелек өлкәсендә өлкән дәүләт инспекторы булган мөдире;

Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенә караган терлекчелектә күзәтчелек буенча секторының бер үк вакытта вазыйфасы буенча Татарстан Республикасының нәселле терлекчелек өлкәсендә дәүләт инспекторы булган төп киңәшчесе.»;

түбәндәге эчтәлекле $11^{1}$ – $11^{5}$ нче пунктлар өстәргә:

«$11^{1}$. Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә карата план буенча тикшерүләр үткәрү, аларның эшчәнлегенә бирелгән риск категориясенә карап, түбәндәге вакытлар дәвамлылыгында гамәлгә ашырыла:

урта рисктагы категория өчен – дүрт елга бер тапкырдан ешрак һәм биш елга бер тапкырдан сирәк булмаган вакыт эчендә;

уртача рисктагы категория өчен – алты елга бер тапкырдан ешрак һәм сигез елга бер тапкырдан сирәк булмаган вакыт эчендә.

түбән рисктагы категория өчен – план буенча тикшерүләр үткәрелми.

$11^{2}$. Министрлык бу Нигезләмәнең $5^{2}$ нче пункты нигезендә эшчәнлегенә рискның билгеле бер категорияләре бирелгән юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр исемлеген (алга таба – исемлек) алып бара.

$11^{3}$. Исемлек түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

эшчәнлеге рискның билгеле бер категориясенә кертелгән юридик затның тулы исеме, индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда);

юридик затның, индивидуаль эшмәкәрнең төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры;

юридик затның адресы, индивидуаль эшмәкәрнең яшәү урыны адресы (кирәк булганда элемтә өчен башка почта адресы), телефоны һәм электрон почта адресы (булганда);

юридик зат, индивидуаль эшмәкәр эшчәнлегенә бирелгән риск категориясе турында мәгълүмат;

Министрлыкның юридик зат, индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү турындагы боерыгы реквизитлары;

Министрлыкның юридик зат, индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү турындагы боерыгын кабул итү өчен нигез булган мәгълүматлар.

$11^{4}$. Юридик зат, индивидуаль эшмәкәр соравы буенча Министрлык мондый сорау кергән көннән 15 эш көненнән артмаган вакыт эчендә аларга аларның эшчәнлегенә бирелгән риск категориясе турында мәгълүмат, шулай ук аларның эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә керткәндә файдаланылган белешмәләр җибәрә.

$11^{5}$. Юридик зат, индивидуаль эшмәкәр Министрлыкка аның эшчәнлегенә элегрәк бирелгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 806 нчы карары белән билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелергә тиешле риск категориясе үзгәрү турында гариза бирергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин